**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кармалка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге составына керүче
Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында

**15 октябрь 2021 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең Югары Кармалка, Чумачка, Түбән Кармалка авылы торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2022 елда Түбән Кармалка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- су белән тәэмин итү урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, павильон урнаштыру, павильон тышлау, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект - смета документлары өчен түләү, хезмәтләр өчен түләү), Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында әлеге эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

- зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (коймаларны урнаштыру (ремонтлау), чүп савытларын урнаштыру, агачларны кисү, коры-

сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) Түбән Кармалка, Югары Кармалка, Чумачка торак пунктларында әлеге эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф. Митякин